# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасы Конституция суды турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2006 елның 26 гыйнварында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» 1992 елның 22 декабрендәге 1708-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, №11-12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, №11; 2001, №7-8; 2003, №10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада:

«Закон» сүзеннән соң «федераль законнар нигезендә» сүзләрен өстәргә;

«статусын» сүзен «хокукый хәленең үзенчәлекләре» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 статьяда «Татарстан Республикасы Конституциясе» сүзләре алдыннан «федераль законнар,» сүзләрен өстәргә;

3) 8 статьяда «Татарстан Республикасы гражданы» сүзләрен «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданы» сүзләренә алмаштырырга;

4) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 статья. **Судьяга куела торган таләпләр**

Судья депутат, арадашчы судья, арбитр булырга, сәяси партияләргә һәм хәрәкәтләргә керергә, эшкуарлык эшчәнлеген башкарырга, шулай ук судья вазыйфасында эшләүне, фәнни, мөгаллимлек, әдәби һәм башка иҗат

эшчәнлегеннән тыш, бүтән түләүле эш белән бергә алып барырга хокуксыз.»;

5) 13 статьяда «аның» сүзеннән соң «федераль законнар нигезендә» сүзләрен өстәргә;

6) 14 статьяның 2 өлешендә «бары тик» сүзләреннән соң «федераль законнар нигезендә» сүзләрен өстәргә;

7) 30 статьяның 1 өлешендә «Татарстан Республикасы Конституциясенә» сүзләреннән соң «, федераль законнарга» сүзләрен өстәргә;

8) 41 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3) дәүләт пошлинасын түләү турында документ.»;

9) түбәндәге эчтәлекле 42 статья өстәргә:

«42 статья. **Дәүләт пошлинасы**

Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать иткәндә дәүләт пошлинасы федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә алына.»;

10) 43 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4) дәүләт пошлинасы түләнмәгән булса.»;

11) 102 статьяның 2 өлешен төшереп калдырырга;

12) 107 статьяны төшереп калдырырга;

13) 112 статьяның 1 өлешендәге икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Конституция суды утырышлары залында Россия Федерациясе Дәүләт флагы, Татарстан Республикасы Дәүләт флагы һәм Россия Федерациясе Дәүләт гербы, Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәтләре законнарда билгеләнгән тәртиптә урнаштырылалар.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан, Кремль
2006 елның 20 феврале

№ 14-ТРЗ

Исп., тел.:
C:\ILSIA\PEREBOD\Sakon\2006\Консти-уэ-2ук.doc